БЕЗДӘ ШУЛАЙ — СЕЗДӘ НИЧЕК?

# КҮҢЕЛГӘ ЯЗЛАР КИЛГӘЧ



Тольятти шәһәрендә инде гадәткә кергән, тамашачыга таныш «Язлар моңы» фестивале татарларны тагын да бергә җыйды. 17 апрель көнне шәһәр филармониясе татар сәнгатенә битараф булмаган кешеләр белән тулды. Тальян моңын сөючеләр дә, татар биюләрне, җырларны яратучылар да бүген бер зур тамаша залына җыелганнар. Биредә өченче тапкыр татар үзешчән сәнгать фестивале «Язлар моңы» үткәрелде. Фестивальне оештыручылар: Тольятти шәһәре милли-мәдәни автономиясе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм шәһәр мәдәният идарәсе Департаменты кулыннан килгән бөтен эшне башкардылар.

Биредә Тольятти, Самара, Сызрань шәһәреннән, Әсәкәй, Гали һәм Шентала авылларыннан килгән катнашучылар дүрт номинациядә көч сынашты: фольклор, татар халык музыка коралларында уйнау, татар биюләре һәм җырлары. Быелгы фестивальнең аермасы — балаларның катнашуы, әлбәттә, үзләренең бәйгесендә.

Тольятти татар милли-мәдәни мөхтәрияте, сәнгать эшләрен алып баручы Алфия Еникеева әйтүе буенча: «Быел яңалыклар бик күп булды. Алар арасында, минем өчен, иң мөһим булган — балалар бәйгесе. Балалар — безнең киләчәгебез. Әгәр дә телне, мәдәниятне югалтасыбыз килми икән, сәләтле балаларны без үстерергә тиешбез. Шул ук вакытта фестивальнең дәрәҗәсе дә күтәрелеп бара. Беренчедән, номинация саны артты. Башта ул ике генә булса, хәзер алар дүрт булды. Икенчедән, фестивальгә ерак араларны якын итеп килгән Әсәкәй үзешчән сәнгать осталары профессиональ дәрәҗәдә чыгыш ясадылар».

Фестиваль бик тантаналы башланып китте. Сәхнәдә шәһәрнең Балакирев исемендәге милли уен кораллы оркестры үз осталыгын күрсәтте. Соңыннан Тольятти җәмигъ мәчетенең имамы Ислам Гомәров «Язлар моңы» бәйгесенә үз фатихасын бирде.



Беренче чиратта балалар конкурсы узды. Матур тавышлы җырчылар, оста гармунчылар, күбәләк сыман җиңел биючеләр — барысы 14 яшьтән дә зур түгелләр, ә иң кечкенәсе — Азат Зәйдуллин — 5 яшьлек кенә бала иде.

Фестиваль кысаларында Бөек Җиңүнең 65 еллык юбилее дә искә алынды.

Әсәкәй районының «Чишмә» халык фольклор ансамбеле Тольяттига «Шәл бәйләдем» һәм «Кинәле буенда» музыкаль композицияләрне алып килделәр. Рафаэль Вагизов милли уен коралларының берсе — гармунда уйнап үз осталыгын күрсәтте. Ә ике яшь җырчы — Ришат Мухаметзянов һәм Радик Ганиев Тольятти кызларын бөтенләй таң калдырдылар.

Мәртәбәле жюри әгъзалары Фердинанд Сәлахов җитәкчесендә, үзләренең гадел фикерен әйттеләр. Гомумән, әлеге фестивальдә катнашкан беркем дә игътибардан читтә калмады. Һәрберсенә катнашу дипломы һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. «Татар җыры» номинациясендә беренче урынны Әсәкәй районы Тамьян егете Ришат Мухаметзяновка алды, ә Радик Ганиев шул ук номинациядә дипломант исеменә лаек булды. «Милли уен коралларында уйнау» номинациясендә Рафаэль Вагизов икенче урын иясе булды. Ә инде данлыклы халык фольклор ансамблебез «Чишмә» Гран — прига лаек булды һәм бүләкне Әсәкәй җиренә алып китте.

**Алсу ХАФИЗ.**

### ФЕСТИВАЛЬ БУЕНЧА ФИКЕРЛӘР:

**Фестиваль бары тик уңай хисләр генә калдырды. Оештыру ягыннан да барысы бик ошады. Кураторлар безгә бик зур ярдәм күрсәттеләр, гомумән, бик җылы каршы алдылар. Минем фикеремчә, Тольятти фестивале иң яхшы фестивальләрнең берсе. Катнашучылар дәрәҗәсе дә бик зур иде.**

**Альмира ГАЛЯУТДИНОВА.**

**«Язлар моңы» якты хатирәләр генә калдырды. Беренчедән, без җиңдек! Һәм бу безнең активта инде икенче Гран — при! Икенчедән, оештыручыларның һәм тамашачыларның күңел җылылыгы бик ошады. Тольятти халкы бик ачык һәм ярдәмчел кешеләр икән.**

**Анжелика ШАРИПОВА.**

# Национальная связь поколений

Татарская диаспора в Пономаревском районе сосредоточена в двух селах — Наурузово и Дюсметьево. Объединившись в населенные пункты, татары живут в маленьком национальном мире, стараясь сохранить свои исторические традиции и обычаи. Благодаря своей численности и сплоченности, они остаются значимой частью населения района, с которой считаются, которая влиятельна в общественной и политической жизни.

В селе Наурузово проживают чуть более 2 тысяч человек, они, несмотря на реформы и кризис, не растеряли чувства национального достоинства и самосознания. Село является крепким, о чем свидетельствуют рост числа подворий и темпы строительства новых домов. Около 700 татар проживают в Дюсметьево. И хотя местный колхоз «приказал долго жить», жители не опустили рук. Быстро нашли ориентиры в новых экономических отношениях. Кто-то занялся предпринимательством, кто-то разведением скота. Серьезное производство сельхозпродукции сохранилось в ООО « Маяк» и пяти крестьянско-фермерских хозяйствах.

Разумеется, не только занятость населения и его самостоятельность, предприимчивость, позволяют сохранять национальные традиции, язык и культуру. Основа закладывается не только в семье, но и в средних школах. С1 по 11 класс здесь изучают родной татарский язык и литературу. Причем обучение этих предметов поставлено на достаточно хорошем уровне. Не зря же наурузовские и дюсметьевские учащиеся каждый год становятся победителями областных и региональных олимпиад по родному языку. Еще одним признанием достижений в обучении предмета стал областной семинар учителей татарского языка, проходивший на базе Наурузовской школы. Наурузовский опыт преподавания сочли необходимым перенять учителя из других районов и города Оренбурга.

Этнографические кружки и кружки родного языка в обеих школах существуют не на бумаге. Именно занимаясь в них, дети узнают многое о истории и культуре своего народа, о истории танцев, о народных песнях. Неудивительно, что и в клубах этих сел функционируют фольклорные и народные группы. Самодеятельные артисты в этих коллективах — выпускники этих школ. Свое творчество они несут зрителям из поколения в поколение, сохраняя дух народа, его самобытность. Отрадно еще то, что эти села не теряют связи со своей исторической Родиной — Татарстаном. Ежегодные экскурсии в город Казань, участие в республиканских фестивалях, отдых в республиканском лагере оставляют в памяти детей неизгладимые впечатления. А за молодым поколением, как известно, будущее наших сел.

**И.СУЛЕЙМАНОВА,**
**Пономаревский район.**

# Хөрмәтле «Туган як» газетасы хезмәкәрләре!

Сезнең басманы бик яратып укыйм һәм үземнең дә кулыма ак кәгазь белән каләм алып язарга булдым.

Газетаның баш мөхәррире Ф.Нугумановның мәкаләсен укып таң калдым. Чынлап та, кризис чорында басмаларда кыенлыклар кичерә. Бүгенге көндә барысыда акчага эшләнә: газетаны чыгару, типографияда басмалау, хезмәт хакы һәм төрле налоглар түләү кесәне юкарта. Шуңа да карамастан, күпләребез арасында укыла торган милли газетабыз чыгып килә һәм укучыларга таратыла. Әйткәндәй, татар авылларына бушлый бирелә 10 экземпляр.

Фәрит әфәнденең мәкаләсе белән мин ризалашам. Газетаны бушка таратырга күп акча кирәк. Ә язылу бәясе «Туган як»ка кыйммәт түгел — 94 сум, 100 сумга да тулмый. Безнең өчен бу зур акча түгел. Ай саен пенсионерларга акчаны китереп торалар, эшләгән кешеләргә дә хак түлиләр. Шулай булгач, газетага барып язылуга бер нинди кыенлыклар комаучамый. Без бүген үзебезнең телебезне, милләтебезне, гореф-гадәтләребезне саклауга зур көч куярга тиешбез һәм татар «Туган як» газетасыннан аерылу безнең уйда булмаса ярар иде дигән теләктә каласы килә. Ә шуның өчен, басмага язылсак, без газетабызны тагын да күп еллар яшәр һәм безне сөендерер торыр дигән теләктә каласыбыз килә.

**Артур НИЗАМОВ,**
**Матвеевка районы.**